**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Вахит авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Җиңү бистәсе №82/48 « 15» декабрь 2022 ел

**2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты турында**

**Статья 1**

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2 478,7 мең сумм итеп;

2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2 478,7 мең сумм итеп;

3) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум итеп.

2. 2024 елга һәм 2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2 508,7 мең сум һәм 2025 елга 2 538,1 мең сум итеп;

2) 2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2 508,7 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 59,5 мең сум итеп һәм 2025 елга 2 538,1 мең сум шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарын 120,1 мең сум итеп;

3) 2024 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты кытлыгын 0,0 мең сум һәм 2025 елга 0,0 мең сум итеп.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**Статья 2**

1. 2024 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2025 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2026 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча эчке бурычының иң югары чиге Россия Федерациясе валютасында 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетында 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

**Статья 4**

1. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Карарның 6 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасының Азнакай муниципаль районы программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2023 елга 0,0 мең сум, 2024 елга 0,0 мең сум һәм 2025 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетында 2023 елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотация 333,3 мең сум, 2024 елга 339,3 мең сум, 2025 елга 346,9 мең сум, күләмендә исәпкә алырга.

**Статья 6**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетында 2023 елга Азнакай муниципаль районы бюджетыннан алына торган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенцияләр күләмен 126,4 мең сум күләмендә, 2024 елга 132,4 мең сум күләмендә, 2025 елга 137,2 мең сум күләмендә исәпкә алырга кирәк.

**Статья 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге муниципаль казна учреждениеләре яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирүгә бәйле рәвештә карарлар кабул итү очракларыннан тыш, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокукысыз.

**Статья  8**

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы казначылык Департаментының Азнакай районы һәм шәһәре буенча территориаль булекчәсе төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**Статья 9**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге бюджетының 2023 елның 1 гыйнварына калган акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактларның шартлары нигезендә товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, 2022 елда түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар суммасыннан артмаган күләмдә, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**Статья 10**

Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

**Статья 11**

Әлеге Карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Статья 12**

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.И. Аскарова